| СОВЕТ<br>САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

22.10.2020 Сарсак-Умга авылы № 3-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварендәге 52-1 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварендәге 52-1 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16.3 пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.2. 20 бүлекнең 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру»;.

2. Карар 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Карарны Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуния челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С. Николаева